ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# 2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

2016 елның 1 гыйнварына кадәр түбәндәгеләрнең гамәлдә булуын туктатып торырга:

1) план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын (Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын) һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын) төзүгә һәм раслауга, план чорына күрсәтелгән Татарстан Республикасы закон проектлары белән бергә документларны һәм материалларны (Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеш фаразыннан, Татарстан Республикасы бюджет сәясәтенең төп юнәлешләреннән һәм Татарстан Республикасы салым сәясәтенең төп юнәлешләреннән тыш) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертүгә карата Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезләмәләренең (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш);

2) Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $52^1$ статьясындагы 5 һәм 6 пунктларының, 53 статьясындагы 2 пункты 5 пунктчасының, 61 статьясындагы 4 пункты унтугызынчы абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009,

№ 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш).

**2 статья**

2016 елда түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы бюджеты (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты) акчаларын алучы тарафыннан бюджет йөкләмәләренең элек бирелгән лимитлары нигезендә 2017 елда түләнергә тиешле йөкләмәләр кабул ителгән шартнамәләр Татарстан Республикасы бюджеты (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты) акчаларын алучыга күрсәтелгән елга бюджет йөкләмәләре лимитлары бирелмәүгә бәйле рәвештә аның инициативасы белән өзелми;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срокларыннан арткан чорга Татарстан Республикасы бюджет йөкләмәләрен барлыкка китерүгә бәйле шартнамәләр (килешүләр) төзелергә мөмкин.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 17 октябре
№ 84-ТРЗ